ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Гоголя, д.1, с.Акбаш, 423958

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Гоголь урамы, 1 йорт, Акбаш авылы, 423958

Тел./факс: (85593) 4-14-34, e-mail: Akbash.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№10** **«04 » август 2016 ел**

**Сайлау участоклары территориясендә**
**басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар**
**бүлеп бирү һәм җиһазлау турында**

ТР Ютазы районы территориаль сайлау комиссиясенең «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына депутатлар сайлау буенча басма агитация материаллары урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар исемлеге турында» гы тәкъдимен карап, «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына депутатлар сайлау турында» гы Федераль законның 68 маддәсендәге 9 өлеше, Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 маддәсендәге 8 пункты нигезендә, Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге башкарма комитеты, Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2016 елның 18 сентябрендә Россия Федерациясе Федераль җыелышы Дәүләт Думасына җиденче чакырылыш депутатлар сайлау буенча басма агитация материаллары урнаштыру өчен сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү.

2. Махсус урыннар бүлеп биргәндә түбәндәгеләрне карарга:

- сайлаучыларны урнаштыру һәм урнаштырылган мәгълүмат белән таныштыру өчен уңайлы;
- теркәлгән кандидатларның басма агитация материалларын урнаштыру өчен тигез һәм җитәрлек мәйдан;
- сайлау комиссияләренең мәгълүмати материалларын урнаштыру өчен җитәрлек мәйдан;

3.Объектларда махсус урыннар урнаштыру шартлары турындагы мәсьәләне аларның хуҗалары белән килештерергә;

4.Басма агитация материалларын урнаштыру өчен бүлеп бирелгән урыннарны һәм алар янәшәсендәге территорияләрне санитар тәртиптә тотуны тәэмин итәргә.

5.Ютазы муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенә басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар урнаштыру урыны турында мәгълүмат бирергә.

6. Әлеге карарны түбәндәге веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: www.yutaza.tatar.ru.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Акбаш авыл җирлеге башлыгына йөкләнде.

Акбаш авыл җирлеге башлыгы: И.М.Миңнеханов

1 санлы кушымта

## Басма сайлау алды агитация материалларын урнаштыру урыннары

## 2798 санлы сайлау участогы

**Акбаш авылы, Совет урамы, 10а адресы буенча урнашкан сайлау алды агитация материаллары урнаштыру өчен урыннар**
**Ютазы районы кулланучылар берлеге кибете бинасы.**